**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әлкәй авылы №56 08 июнь 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең 2014 елнын 13 ноябрендәге 93 номерлы «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» , шулай ук Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июненедәге №50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында,

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең 2014 елның 13 ноябрендәге 93 номерлы «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» , шулай ук Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» карары үз көчен югалткан дип танырга;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең Әлкәй мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәис С.З.Зиннурова